ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2025 г. Казань № 2-1/тэ-2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга 2024-2028 елларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Бөгелмә муниципаль районы кулланучыларына бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2024 елга тарифлар билгеләү турында» 13.12.2023 ел, №566-67/тэ-2023 карарының үз көчен югалтуын тану турында» 21.08.2024 ел, №45-6/тэ-2024 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 29.01.2025 ел, №1-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга 2024-2028 елларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Бөгелмә муниципаль районы кулланучыларына бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2024 елга тарифлар билгеләү турында» 13.12.2023 ел, №566-67/тэ-2023 карарының үз көчен югалтуын тану турында» 21.08.2024 ел, №45-6/тэ-2024 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча

дәүләт комитетының 19.12.2024 ел, №652-98/тэ-2024 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә 2024-2028 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.»;2 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.01.2025 № 2-1/тэ-2025
карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2024-2028 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Ягулыкның чагыштырма сарыфы | Җылылык челтәренең матди характеристикасына технологик югалтулар күләменең мөнәсәбәте | Технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | шартлы ягулык кг/Гкал | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| Бөгелмә муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Бөгелмә җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте | 2024 | 143 204,91 | 1 | - | - | - |
| | | 2025 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2026 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2027 | X | 1 | - | - | - |
| | | 2028 | X | 1 | - | - | - |